| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 29 апреле № 12/86/4-2025

Лениногорск муниципаль районына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2025 елның 23 апрелендәге 1-31/6492 номерлы авыл һәм шәһәр җирлекләре вәкаләтләрен тапшыру турындагы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Иске Иштирәк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районының вәкиллекле органына исәпкә алу буенча вәкаләтләр кабул итү, шулай ук муниципаль мөлкәт һәм авыл җирлегенең җир ресурслары белән эш итү турындагы тәкъдимне карауны тәкъдим итәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советына карауга җибәрергә.

3. Әлеге карарны Иске Иштирәк авылы үзидарә администрациясе бинасында Мәктәп ур., 15 йорт; Ялтау авылында Тынычлык ур., 27 йорт; Бәкер авылында, Таулы ур., 38 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Иске Иштирәк авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.А.Вәлиәхмәтов